| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.08.2013 № 10-26/кс

Казан ш.

***Эчәргә яраклы суга һәм техник суга тарифларны билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм техник суга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 1 сентябреннән 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. »Техник суга, эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләү турында» 2013 елның 31 маендагы 10-18/кс номерлы Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарына кушымтага түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8 | «Нефтебаза» ТМШ | 31,10 | | 28,28 | |

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
02.08.2013 № 10-26/кс
карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм техник суга тарифлар

| Тәртип саны | Салкын су белән тәэмин итүче оешма исеме | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Алабуга муниципаль районы | | |
| 1 | Иске Юраш авыл җирлегенең «Халыкка хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе* | 24,59 | |
| | Казан шәһәре | | |
| 2 | «РЖД» ААҖ филиалы – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) | | 26,83 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм